- Тема: Арча районы күренекле шәхесләрнең иҗаты аша сыйфат, аның дәрәҗәләре темасын кабатлау.
- ( интеграль дәрес)

# *Максат:*

1) Сыйфат сүз төркеме турында белемнәрне тирәнәйтү, гомумиләштерү;
2) Алган белемнәрне куллану күнекмәләре үстерү;
3) Якташ язучыларыбызның иҗаты белән кызыксыну уяту, балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләү.

# Арча гимны

Бөек Тукай Ватаны, син, Арча!
Мөхәммәтләр Ватаны, син, Арча!
Ай – йолдызлар Ватаны, син, Арча!
Ватанымның ал таңы, син, Арча!

Җидегән чишмәләрдән ургылган моң,
Яшьлегеңә, кыйбла ача!
Мәрҗәнилар, Курсавилар рухы,
Гыйлем тавы булып алга баса.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;

Күз ачып йомганчы һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр

Берле бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гөнҗәләр.

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр.

Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берле бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гөнҗәләр.
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр.
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Тип-тигез, киң асфальт юл. Бертуктаусыз машиналар, автобуслар үтеп тора. Ә юлның ике ягында алмагачлар. Алмагачлар яшь әле, бәләкәй әле. Әмма шундый көр булып, нык булып үсеп киләләр. Күз аларың яфрагын яки күлмәген төрле төскә бизәгән. Тукта, әнә тәге алмагачта алма да бар түгелме? Әйе, кып-кызыл, түп-түгәрәк алма. Арырак әнә тагын бер алмагачта алма күренә, әйтерсең үзенә дәшә. (Р.Төхвәтуллиннан)